| МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

01.07.2015 № 283

**Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте урыннарында булган хезмәткәрләргә счетлар (кертемнәр) ачуны һәм тотуны, кулдагы акчаны һәм кыйммәтле әйберләрне Россия Федерациясе чигеннән тышта булган чит ил банкларында саклауны, чит ил финанс инструментлар тотуны һәм (яисә) куллануны тыя торган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте урыннарының исемлеген раслау турында**

"Аерым шәхес категорияләренә счетлар (кертемнәр) ачуны һәм тотуны, кулдагы акчаны һәм кыйммәтле әйберләрне Россия Федерациясе чигеннән тышта булган чит ил банкларында саклауны, чит ил финанс инструментлар тотуны һәм (яисә) куллануны тыю турында" 2013 ел 7 нче май № 79-ФЗ Федераль законының 1 мәкалә 1 бүлек 1 пункт "и" пункт астына һәм "Коррупциягә каршы килү буенча кайбер мәсьәләләр турында" 2015 ел 8 нче март № 120 Россия Федерациясе Президенты Указының 2 пунктына туры китереп, "Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте урыннарында булган хезмәткәрләргә счетлар (кертемнәр) ачуны һәм тотуны, кулдагы акчаны һәм кыйммәтле әйберләрне Россия Федерациясе чигеннән тышта булган чит ил банкларында саклауны, чит ил финанс инструментлар тотуны һәм (яисә) куллануны тыя торган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте урыннарының исемлеген раслау турында" 2015 ел 8 нче июнь № УП-542 Татарстан Республикасы Президенты Указын үтәү йөзеннән боерык бирәм:

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте урыннарында булган хезмәткәрләргә счетлар (кертемнәр) ачуны һәм тотуны, кулдагы акчаны һәм кыйммәтле әйберләрне Россия Федерациясе чигеннән тышта булган чит ил банкларында саклауны, чит ил финанс инструментлар тотуны һәм (яисә) куллануны тыя торган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте урыннарының исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге башлыгына С.В. Зайцевка:

биредәге Боерыкны чыгарган вакыттан өч көн эчендә Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында теркәлгән Исемлеккә туры килгән урыннарда булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен биредәге боерык белән кул кую нигезендә таныштырырга;

Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына һәм Коррупциягә каршы килү полтикасы мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президенты идарәсенә биредәге Боерык белән расланган Исемлекне раслау көненнән алып өч көн эчендә, ә аннары аңа үзгәрешләр керткәндә төзәтелгән исемлекләрне үзгәрешләр кертелгән вакыттан алып атна эчендә китерергә.

3. Биредәге Боерыкны үтәү контролен үземә калдырам.

Министр Р.Җ. Хәбибуллин

01.07.2015 ел № 283
Татарстан Республикасы ГТХМ боерыгы
белән расланган

**Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте урыннарында булган хезмәткәрләргә счетлар (кертемнәр) ачуны һәм тотуны, кулдагы акчаны һәм кыйммәтле әйберләрне Россия Федерациясе чигеннән тышта булган чит ил банкларында саклауны, чит ил финанс инструментлар тотуны һәм (яисә) куллануны тыя торган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте урыннарының исемлеге**

| № т/б | Урын исеме |
|---|---|
| 1 | Министр урынбасары |